| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 13 марты Кукмара ш. № 277

Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләре муниципаль милкендәге һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән мөлкәт белән эш итү (җир кишәрлекләрен дә кертеп) буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 тиюнендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең вәкиллекле органнарының Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ______________ авыл җирлеге муниципаль милкендәге һәм өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән мөлкәт белән (җир кишәрлекләрен дә кертеп) эш итү буенча;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (www.kukmor.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ______________ авыл җирлеге муниципаль милкендәге күчемсез милек объектлары турында, кече эшмәкәрлек субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәтне күрсәтеп, мәгълүмат бастыру буенча.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл

җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Кушымта нигезендә типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Район башлыгы Димитриев С. Д.

Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елның ___________ _____ номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ______________ авыл җирлекләре муниципаль милкендәге һәм муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән мөлкәт белән (җир кишәрлекләрен дә кертеп) эш итү буенча ______________ авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында КИЛЕШҮ

______________ авыл җирлеге Башкарма комитеты, алга таба «Авыл җирлеге башкарма комитеты» дип аталучы. ______________ авыл җирлеге башлыгы ________________________ исеменнән, гамәлдәге Устав нигезендә, бер яктан, район Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы, алга таба «Район палатасы» дип аталучы, Кукмара муниципаль районы Уставы һәм Кукмара муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы Положениесе нигезендә эш итүче Кукмара муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Закиров И. Г. исеменнән, икенче яктан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү район Палатасына җирлек башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлек башкарма комитеты район Палатасына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлек башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыра:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ______________ авыл җирлеге муниципаль милкендәге һәм өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән мөлкәт белән (җир кишәрлекләрен дә кертеп) эш итү буенча;
- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (www.kukmor.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ______________ авыл җирлеге муниципаль милкендәге күчемсез милек объектлары турында, кече эшмәкәрлек субъектларына милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәтне күрсәтеп, мәгълүмат бастыру буенча

2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

2.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

2.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары елына ____________ мең сум күләмендә билгеләнә.

2.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә.

2.4. Район Палатасы тарафыннан финанс чаралары максатсыз файдаланылган очракта, алар җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн срокта җирлек бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Район палатасы, әлеге Килешүнең 1 бүлеге һәм гамәлдәге законнар нигезендә, җирлек Башкарма комитеты тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне башкара.

3.2. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон һәм норматив хокукый актларында каралган срокларда һәм күләмнәрдә мәгълүмат алмашырга бурычлы.

3.3. Җирлек Башкарма комитеты район Палатасына тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларының максатчан кулланылышын контрольдә тота ала.

4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, гамәлдә булуын туктату нигезләре һәм тәртибе

4.1. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

4.2.1. Яклар килешүе буенча.

4.2.2. Берьяклы тәртиптә:

- әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, шул исәптән Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Татарстан Республикасы законнары үзгәргән очракта;

- район Палатасы тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрнең тиешенчә башкарылмавы (яки башкарылмавы), субвенцияне максатсыз куллану очрагы ачыкланган очракта, башка Якка 1 ай алдан хәбәр итү шарты белән җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча.

4.3. Килешүне өзү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

4.4. Әгәр Яклар әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән срок узганнан соң утыз көн эчендә Килешүне өзү нияте турында белдермиләр икән, ул шундый ук яңа срокка төзелгән дип санала.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

5.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе тарафынннан йөкләмәләр үтәлмәгән өчен гаепле Як икенче Якка әлеге Килешүнең 2.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

5.3. Район Палатасы тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау фактын билгеләү әлеге Килешүнең берьяклы өзелүенә нигез булып тора. Килешүне өзү документта расланган факттагы чыгымнарны исәпкә алып, Килешүне өзү

яки Килешүнең өзелүе турында язма хәбәр алынганнан соң 30 көн эчендә санап үтелгән бюджетара трансфертларны кире кайтаруга китерә.

5.4. Район Палатасы үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен, әлеге вәкаләтләрнең финанс чаралары белән тәэмин ителеше дәрәҗәсендә җаваплылык тота.

5.5. Якларның әлеге Килешүдә каралмаган җаваплылык чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нормалары нигезендә кулланыла.

## 6. Башка мәсьәләләр

6.1. Якларның үзара килешүе буенча яисә гамәлдәге закон таләпләре нигезендә, Яклар кул куйганнан соң, язма рәвештә әлеге Килешүгә аның аерылгысыз өлеше булган үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән Яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә тикшерелергә тиеш.

6.3. Әлеге Килешү 2 (ике) нөсхәдә, тигез юридик көчкә ия булган һәр Як өчен бер нөсхәдә төзелде.

## 7. Яклар адреслары һәм башка мәгълүмат

| | |
|---|---|
| «Авыл җирлеге башкарма комитеты» | «Район палатасы» |
| ___________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты | Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы |